ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23 декабрь 2025ел № 10847

Башкарма комитетның «Дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннарыннан файдалануга түләү (наем өчен түләү), торак урынны карап тотуга һәм ремонтлауга түләү күләмен һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар һәм (яки) торак урынны карап тотуга түләү күләме билгеләү турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында» 2025 елның 31 октябрендәге 8919 номерлы Карары кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясының 3, 4 өлешләре, 158 статьясының 4 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы Карары белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләренең 35 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итү өчен кирәкле хезмәтләрнең һәм эшләрнең минималь исемлеге, аларны күрсәтү һәм башкару тәртибе турында» 2013 елның 3 апрелендәге 290 номерлы Карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, «2025 елның 1 ноябреннән 2026 елның 31 октябренә кадәр чорга Яр Чаллы шәһәре халкы өчен, муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен, гомуми җыелышта торак урыннарын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак милекчеләре өчен күпфатирлы йортларда вентиляция каналларына һәм төтен юлларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау хезмәтләренә түләү (бәяләр) күләме турында тәкъдимне исәпләү буенча эксперт бәяләмәсе» 2025 елның 6 октябрендәге 25/57-ЭЭ номерлы хисабы, «2026 елга эшләрнең бәясен исәпләү-нигезләү» 2025 елның 9 сентябрендәге 10-Э-2025 номерлы бәяләмәсе нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннарыннан файдалануга түләү (наем өчен түләү), торак

урынны карап тотуга һәм ремонтлауга түләү күләмен һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар һәм (яки) торак урынны карап тотуга түләү күләме билгеләү турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында» 2025 елның 31 октябрендәге 8919 номерлы Карары кушымтасына, түбәндәге эчтәлектәге 4.10, 4.11, 6 пунктлар өстәп, үзгәрешләр кертергә:

| № т/б | Түләү исеме | Хезмәтне үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф, сумнарда |
|---|---|---|---|
| 4 | Төзелеш корылмаларына һәм биналарның инженерлык системаларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау, шул исәптән: | | |
| 4.10. | вентиляция каналларына | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 0,37 |
| 4.11. | төтен юлларына | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 0,68 |
| 6. | Йорт эчендәге газ җиһазына техник диагностика ясау (түләүне исәпләү диагностикалауны үткәрү срогы башланганчы 12 ай дәвамында башкарыла) | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 0,85 |

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»
УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Ф.Ш. Салахов